**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **с. Тюлячи** **КАРАР**

**«27» декабре 2024ел** **№ 178**

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 10 декабрендәге 552 номерлы карары белән расланган «2021-2026 елларга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында муниципаль хезмәтне үстерү» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 10 декабрендәге 552 номерлы карары белән расланган (29.12.2021 № 326, 13.12.2022 № 269, 14.12.2023 № 187 карарлар редакциясендә) «2021-2026 елларга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында муниципаль хезмәтне үстерү» муниципаль программасына (алга таба - Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Программаның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2021-2027 елларга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында муниципаль хезмәтне үстерү» муниципаль Программасы;

1.2. Программага, түбәндәге эчтәлектә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 10 декабрендәге
552 номерлы карары
(«27» 12 2024 № 178
карар редакциясендә) белән
расланган

**«2021-2027 елларга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында муниципаль хезмәтне үстерү» муниципаль программасы**

**Программа паспорты**

| | |
|---|---|
| Программа атамасы | «2021-2027 елларга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында муниципаль хезмәтне үстерү» муниципаль Программасы (алга таба - Программа) |
| Муниципаль заказчы | Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаны төп эшләүче | Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаның максатлары | 1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнарының (алга таба - җирле үзидарә органнары) үзләренә йөкләнгән вәкаләтләрне үтәүнең нәтиҗәлелеген арттыру.<br>2. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында муниципаль хезмәттә кадрлар эшенә заманча технологияләр кертү (алга таба-муниципаль хезмәт) |
| Программаның бурычлары | 1. Җирле үзидарә органнары аппаратлары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру, шул исәптән аларның оештыру структурасын һәм штат санын камилләштерү аша.<br>2. Теләче муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләрен (алга таба – муниципаль хезмәткәрләр) сайлап алу, эшчәнлекне комплекслы бәяләү һәм аларны алга этәрү буенча нәтиҗәле механизмнарны гамәлгә кертү (алга таба-муниципаль хезмәткәрләр).<br>3. Муниципаль хезмәткәрләрнең, шулай ук кадрлар резервларына кертелгән затларның һөнәри һәм идарә компетентлыгын үстерү.<br>4. Муниципаль хезмәттә мотивация, стимуллаштыруның нәтиҗәле системасын төзү.<br>5. Муниципаль хезмәткә яшь, перспективалы белгечләрне җәлеп итү һәм беркетү.<br>6. Җәмәгать контроле системасын үстерү һәм граждан җәмгыяте институтлары белән үзара хезмәттәшлек итү, муниципаль хезмәттә коррупциягә каршы тору чараларын гамәлгә ашыру.<br>7. Муниципаль хезмәтне норматив һәм методик тәэмин итү |
| Программаны тормышка ашыру сроклары | 2021-2027 еллар |

| | |
|---|---|
| Программаны финанслау күләме еллар буенча | Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы бюджеты хисабына программаны финанслауның гомуми күләме 2053,55 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>2021 елда - 222,01 мең сум;<br>2022 елда - 145,11 мең сум;<br>2023 елда - 280,32 мең сум;<br>2024 елда - 288,71 мең сум;<br>2025 елда - 366,50 мең сум;<br>2026 елда - 372,40 мең сум;<br>2027 елда - 378,50 мең сум |
| Программаны гамәлгә ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре | Программаны тормышка ашыру 2027 елга түбәндәгеләргә мөмкинлек бирәчәк:<br>1. Җирле үзидарә органнары аппаратлары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру.<br>2. Муниципаль хезмәткәрләрнең аларның һөнәри эшчәнлекләренең нәтиҗәлелеген күтәрүгә һәм муниципаль хезмәттә югары квалификацияле кадрларны тотып калуга мотивациясен көчәйтергә, шул исәптән хезмәт өчен түләү системасын һәм муниципаль хезмәткәрләрне социаль яклау чараларын камилләштерергә.<br>3. Муниципаль хезмәт мәсьәләләре буенча норматив хокукый базаны актуальләштерергә, җирле үзидарә органнарының кадрлар белән тәэмин ителешен камилләштерү буенча оештыру һәм методик эш алып барырга.<br>4. Муниципаль хезмәткәрләрнең тормышын һәм сәламәтлеген иминиятләштерү.<br>5. Муниципаль хезмәткәрләрнең еллык диспансеризациясен үткәрү |

## I. Программаны гамәлгә ашыру өлкәсенә характеристика, төп проблемалар һәм аларны хәл итү юллары

Муниципаль берәмлекнең һәм тулаем дәүләтнең динамик үсешенең мөһим шарты-муниципаль идарәнең нәтиҗәле төзелгән системасы.

Хәзерге вакытта муниципаль идарә системасын камилләштерүнең өстенлекле юнәлешләре булып муниципаль хезмәтнең кадрлар потенциалын үстерү, муниципаль хезмәтләрнең сыйфатын һәм һәркем өчен мөмкин булуын арттыру, муниципаль хезмәт өлкәсендә кадрлар сәясәтенең яңа принципларын кертү тора.

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында муниципаль хезмәт белән идарә итү тәҗрибәсе тупланган, муниципаль хезмәткә керү, узу

һәм туктату, шулай ук муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри үсеше өчен шартлар тудырылган.

Муниципаль хезмәткә персоналны сайлап алу муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә һәм кадрлар резервыннан конкурслар үткәрү процедурасы аша башкарыла, бәйсез экспертларның һәм районның Иҗтимагый советы вәкилләренең аттестация, конкурс комиссияләрендә һәм муниципаль хезмәттә үз-үзләрен тоту таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссияләрендә катнашуы тәэмин ителә.

Федераль законнарның, Татарстан Республикасы законнарының, шулай ук муниципаль хезмәт өлкәсендә мөнәсәбәтләрне җайга салучы муниципаль норматив хокукый актларның үтәлешенә даими мониторинг үткәрелә.

Хәзерге вакытта дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең бердәм хезмәт хакы системасы эшли. Әлеге система стажны, класс чины, биләгән вазыйфаның категориясен исәпкә алырга мөмкинлек бирә. Премия бирү, матди ярдәм күрсәтү һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларына өстәмәләр билгеләү тәртибе билгеләнде.

Муниципаль хезмәт Теләче муниципаль районының социаль-икътисади үсеш стратегиясен тормышка ашыруны тәэмин итәргә тиеш.

Заманча муниципаль хезмәткәр үз вазифаларын нәтиҗәле башкарырга, киң күзаллауга, шулай ук төрле аралашу күнекмәләренә ия булырга, үз эшчәнлекләрендә халык мәнфәгатьләренә ориентлашырга тиеш.

Теләче муниципаль районының муниципаль хезмәткәрләре (шул исәптән авыл җирлекләре) 62 кеше.

Хәзерге вакытта муниципаль хезмәт өлкәсенә түбәндәге проблемалар хас:

1) югары квалификацияле кадрлар китү, бу җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген киметүгә китерә, муниципаль хезмәттәге агымнарның югары күрсәткече күзәтелә;

2) муниципаль хезмәткәрләр эшчәнлегенең түбән нәтиҗәлелеге белән бәйле:

- җирле үзидарә органнарының оештыру структураларының җитешсезлекләре;

- муниципаль хезмәткәрләрне мотивацияләү механизмнарының үсмәве;

- муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри хезмәт эшчәнлеген бәяләү механизмнары булмау;

3) муниципаль хезмәтнең имиджын киметү, шул исәптән ачыклыкның җитәрлек дәрәҗәдә булмавы, артык бюрократлаштыру, коррупция факторлары булу аркасында да;

4) заманча мәгълүмати технологияләр кертүнең җитәрлек дәрәҗәдә булмавы.

Шуңа бәйле рәвештә муниципаль хезмәт өлкәсен модернизацияләү зарурлыгы туа. Муниципаль хезмәттә кадрлар составын көчәйтергә, муниципаль хезмәткәрләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттырырга һәм, нәтиҗә буларак, җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен киләчәктә югары

нәтиҗәле башкаруны тәэмин итәргә сәләтле системалы карарлар кабул итү таләп ителә.

Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советының 2020 елның 09 декабрендәге ПР-187 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль районының җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең структурасын формалаштыру һәм штат санын билгеләү буенча методик тәкъдимнәр эшләнде һәм кулланылды.

Теләче муниципаль районы Советының 2021 елның 07 октябрендәге 80 номерлы карары белән Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Советы аппараты турында нигезләмә расланды, район Советы структурасы методик тәкъдимнәргә туры китерелде.

Теләче муниципаль районы Советының 2021 елның 7 октябрендәге 81 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының структурасын раслау һәм аның хезмәткәрләренең иң чик санын билгеләү турында» карары белән район башкарма комитетының структурасы методик тәкъдимнәргә туры китерелде.

Программаны тормышка ашыру муниципаль хезмәт нигезләрен камилләштерергә, аларның оештырылуын һәм эшләвен оптимальләштерергә, муниципаль хезмәттә заманча кадрлар, мәгълүмати, белем бирү һәм идарә технологияләрен кертергә мөмкинлек бирәчәк.

## II. Программаның максатлары, бурычлары һәм чаралар исемлеге. Программа нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары

Заманча муниципаль хезмәт муниципаль хезмәткәрләрнең нәтиҗәле эшчәнлегенә юнәлдерелгән, конкурентлыкка сәләтле һәм абруйлы булырга, шулай ук гражданлык җәмгыяте институтлары белән актив хезмәттәшлек итәргә тиеш.

Программаның максаты-җирле үзидарә органнары тарафыннан үзләренә йөкләнгән вәкаләтләрне үтәүнең нәтиҗәлелеген арттыру, шулай ук муниципаль хезмәттә кадрлар эшенә заманча технологияләр кертү.

Әлеге максатларга ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү күздә тотыла:

1. Җирле үзидарә органнары аппаратлары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру.

2. Муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри эшчәнлекләренең нәтиҗәлелеген күтәрүгә һәм муниципаль хезмәттә югары квалификацияле кадрларны саклап калуга мотивациясен көчәйтергә, шул исәптән хезмәт өчен түләү системасын һәм муниципаль хезмәткәрләрне социаль яклау чараларын камилләштерергә.

3. Муниципаль хезмәт мәсьәләләре буенча норматив хокукый базаны актуальләштерергә, җирле үзидарә органнарының кадрлар белән тәэмин ителешен камилләштерү буенча оештыру һәм методик эш алып барырга.

4. Муниципаль хезмәткәрләрнең тормышын һәм сәламәтлеген иминиятләштерү.

5. Муниципаль хезмәткәрләрнең еллык диспансеризациясен үткәрү.

Муниципаль хезмәтне үстерү буенча төп чаралар Программаның максатлары һәм бурычлары белән билгеләнә һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы нигезләмәләрен исәпкә алып эшләнде.

Программаны гамәлгә ашыру срогы: 2021-2027 еллар.

Программада каралган максатларны һәм бурычларны гамәлгә ашыру чаралары, шул исәптән Программаның муниципаль заказчы-координаторы һәм башкаручылары вәкаләтләре кысаларында гамәлгә ашырыла торган чаралар, аны гамәлгә ашыру нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары, шулай ук Программаны финанслау күләмнәре аңа кушымтада бәян ителде.

## III. Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Программа чаралары Теләче муниципаль районы бюджеты хисабына тормышка ашырыла. 2021-2027 елларга Программаны финанслау күләме 2053,55 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:

2021 елда - 222,01 мең сум;
2022 елда - 145,11 мең сум;
2023 елда - 280,32 мең сум;
2024 елда - 288,71 мең сум;
2025 елда - 366,50 мең сум;
2026 елда - 372,40 мең сум;
2027 елда - 378,50 мең сум.

«2014-2016 елларга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында гамәлгә ашырыла торган программа чаралары күрсәтелгән дәүләт программасында каралган ассигнованиеләр күләмнәрендә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән финанслана.

Бюджет мөмкинлекләрен исәпкә алып, программаны тормышка ашыруга юнәлдерелә торган акчалар күләме өч еллык чорга Теләче муниципаль районы бюджеты проектын эшләгәндә һәм аны чираттагы финанс елына төгәлләштергәндә тәгаенләнә.

## IV. Программаны гамәлгә ашыру механизмы

Программада каралган чараларны үтәүчеләр - җирле үзидарә органнары.

## V. Программаның икътисади һәм социаль нәтиҗәлелеген бәяләү

Программаны гамәлгә ашыруның икътисадый әһәмиятлелеге,

нәтиҗәлелеге һәм социаль-икътисадый нәтиҗәләре кушымтада күрсәтелгән максатчан күрсәткечләргә ирешү дәрәҗәсенә бәйле.

Программа тарафыннан тәкъдим ителгән чаралар түбәндәге уңай социаль-икътисадый нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:

- җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру;
- муниципаль хезмәткәрләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру;
- муниципаль хезмәтнең ачыклыгын, җәмәгать контролен тәэмин итү;
- муниципаль хезмәткәрләрнең хокукый һәм социаль якланууын тәэмин итү өчен кирәкле шартлар булдыру хисабына муниципаль хезмәтнең җәлеп итүчәнлеген арттыру.

Программа чараларын гамәлгә ашыру муниципаль хезмәтнең югары сыйфат дәрәҗәсенә күчүенә ярдәм итәчәк, бу эшчәнлекнең барлык өлкәләрендә муниципаль идарә итүнең нәтиҗәлерәк механизмын булдырырга мөмкинлек бирәчәк.

Программаны тормышка ашыруның бөтен чорында нәтиҗәлелегенә бәя 2027 елга программаның Кушымтада китерелгән нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары буенча күрсәткечләрне исәпкә алып үткәрелә.

«2021-2027 елларга
Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районында
муниципаль хезмәтне үстерү»
муниципаль программасына
кушымта

**«2021-2027 елларга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында муниципаль хезмәтне үстерү» муниципаль программасының максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашыру чаралары һәм аларның нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары**

## I. Максатчан финанслауны таләп итми торган оештыру һәм норматив-хокукый характердагы чаралар

| № т/б | Төп чараның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү вакыты (ел) | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары | Индикаторлар күрсәткечләре | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2021 ел (база елы) | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел |
| Максат: «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының (алга таба - җирле үзидарә органнары) җирле үзидарә органнары тарафыннан үзләренә йөкләнгән вәкаләтләрне үтәү нәтиҗәлелеген арттыру» | | | | | | | | | | | |
| 1. | Җирле үзидарә органнары аппаратлары структурасына анализ үткәрү | Җирле үзидарә органнары | 2021 | Җирле үзидарә органнары аппаратларының структурасын анализлау нәтиҗәләре буенча хисап һәм аларны камилләштерү буенча тәкъдимнәр төзү, структураны методик тәкъдимнәр белән тәңгәлләштерү | - | - | - | - | - | - | - |
| 2. | Муниципаль | Җирле үзидарә | 2021-2027 | Кадрлар хезмәте | 100% | 100% | 100% | 100% | 100% | 100% | 100% |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт үтүгә бәйле таләпләрне, чикләүләрне һәм тыюларны, шул исәптән коррупциягә каршы тору буенча законнарны үтәүне контрольдә тотуны гамәлгә ашыру | органнары | | тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр һәм башка чаралар саны, керемнәр һәм башка мәгълүмат | | | | | | | |

## II. Максатчан финанслауны таләп итә торган чаралар

| № т/б | Төп чараның исеме | Башкар учылар | Төп чараларны башкару сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары | Индикаторлар күрсәткечләре | | | | | | | Җирле бюджет (Татарстан Республикасы бюджеты) акчалары исәбеннән финанслау, мең сум. | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2021 (база елы) | 2022 | 2023 | 2024 | 2025 | 2026 | 2027 | 2021 (база елы) | 2022 | 2023 | 2024 | 2025 | 2026 | 2027 |
| Максат: «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан аларга йөкләнгән вәкаләтләрне үтәүнең нәтиҗәлелеген арттыру» | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Бурыч: «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең (алга таба - муниципаль хезмәткәрләр), шулай ук күрсәтелгән җирле үзидарә органнарының кадрлар резервына кертелгән затларның һөнәри һәм идарә компетентлыгын үстерү» | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1. | Муниципаль хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрүне, | Җирле үзидарә органнары | 2021-2027 | Квалификация күтәрүгә, тиешле елда һөнәри әзерлек | 100% | 100 % | 100 % | 100 % | 100 % | 100 % | 100 % | ТР бюджеты хисабына | ТР бюджеты хисабына | ТР бюджеты хисабына | ТР бюджеты хисабына | ТР бюджеты хисабына | ТР бюджеты хисабына | ТР бюджеты хисабына |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | һөнәри яңадан әзерләүне оештыру | | | узган муниципаль хезмәткәрләр өлеше | | | | | | | | | | | | | | |
| 2. | Муниципаль хезмәткәрләрнең тормышын һәм сәламәтлеген иминиятләштерү | Җирле үзидарә органнары | 2021-2027 | Иминиятләштерелгән муниципаль хезмәткәрләр өлеше | 100% | 100 % | 100 % | 100 % | 100 % | 100 % | 100 % | | 105,90 | 105,90 | 106,48 | 146,60 | 152,50 | 158,60 |
| 3. | Муниципаль хезмәткәрләрнең еллык диспансеризациясен үткәрү | Җирле үзидарә органнары | 2021-207 | Муниципаль хезмәткәрләр диспансеризациясен узган өлеше | 100% | 100 % | 100 % | 100 % | 100 % | 100 % | 100 % | | 116,11 | 39,21 | 182,23 | 219,90 | 219,90 | 219,90 |

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин